ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.07.2026 г.Лениногорск № 544

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 24 июнендәге 500 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (24.11.2025 №1009 белән редакцияләнгән)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025-2030 елларга Татарстан Республикасында «Актив озак яшәү»республика программасын (комплекслы планын) раслау турында» 2024 елның 26 декабрендәге 1213 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 24 июнендәге 500 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның преамбуласындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар белән» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 24 июнендәге 500 номерлы карары белән расланган 2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасында (комплекслы план) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлекнең 2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2. Программаның бурычлары:»

җәмгыятьтә күп буынлы гаилә кыйммәтләрен, өлкән буынга ихтирамлы мөнәсәбәтне ныгыту;

өлкән буын гражданнарының сәламәтлеген саклау, авыруларны һәм аларның үсеш куркынычы факторларын профилактикалау, өлкән буын гражданнарының, шул исәптән өйдә, медицина ярдәменнән файдалана алуын арттыру, аларда авыруларны диагностикалауның һәм дәвалауның яңа ысулларын кертү, дарулар белән тәэмин итүне яхшырту, өлкән буын гражданнарының актив сәламәт озын гомерен озайту;

өлкән буын гражданнарының шәхси потенциалын тормышка ашыру һәм аларның җәмгыять тормышында катнашуын киңәйтү өчен шартлар тудыру;

өлкән буын гражданнары өчен социаль хезмәтләрне үстерү;

өлкән буын гражданнарының финанс тәэмин ителешен күтәрү, аларны эш белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

өлкән буын гражданнарының сыйфатлы һәм имин тормышы өчен инфраструктураны үстерү.»;

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру чаралары планына түбәндәге эчтәлекле 6.6 юл өстәргә:

| № т/б | Исеме Программа чаралары[1] | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 6.6 | «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына «Лениногорск муниципаль районы» МБ БК «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ, «Лениногорск муниципаль районы» МБ Р «Мәдәният идарәсе» МКУ, «Лениногорск муниципаль районы» МБ БК «Мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан Программада күрсәтелгән мәгълүматны җыюны башкарырга, һәм мәгълүматне Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, | елга ике мәртәбә (20 июльгә кадәр – агымдагы елның беренче яртыеллыгы йомгаклары буенча һәм хисап елыннан соң киләсе елның 20 февраленә кадәр). | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ, «Мәдәният идарәсе» МКУ, «Лениногорск муниципаль районы» МБ БК «Мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына | | |

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: https://Leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: https://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Г. Шәмәрданов

Ю.В. Федотова
5-13-80